# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ОЛЫ КАРАУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2020 елның 28 феврале № 229

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 июлендәге 103 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге № 8-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015елның 16 нчы гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 июлендәге 103 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының «Интернет» челтәрендәге эшчәнлеге турында мәгълүматлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. IV бүлегендә 26 пунктны төшереп калдырырга: «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Яшел Үзән муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Олы Карауҗа авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Олы Кульбаш авылы, Тау Асты урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы), Олы Карауҗа авылы, Купер урамы, 23 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Олы Карауҗа авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

**Олы Карауҗа авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **М.Р.Минһаҗев**